**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г. Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2026 елның15 маендагы 781/ПИК номерлы

# КАРАР

**Җир участогын аерым саклана торган территорияләр җирләренә кертү һәм җирлек әһәмиятендәге рекреация максатларындагы аерым саклана торган территорияләр булдыру турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Җирләрне яисә җир участокларын бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 16 февралендәге 270/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге территориясендә урнашкан, Михайлов Денис Владимировичка милек хокукында караган, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән гомуми мәйданы 11 758 кв.м булган 16:24:030202:1365 кадастр номерлы һәм гомуми мәйданы 84 213 кв.м булган 16:24:030202:1366 кадастр номерлы җир участокларын ял итү (рекреация) объектларын урнаштыру өчен «Аерым саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре»нә кертәргә.

2. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Пелево авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән рөхсәт ителгән файдалану төре «авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен» булган, гомуми мәйданы 11 758 кв.м булган 16:24:030202:1365 кадастр номерлы һәм гомуми мәйданы 84 213 кв.м булган 16:24:030202:1366 кадастр номерлы җир участокларында ял итү (рекреация) объектларын урнаштыру өчен «Аерым саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре»ндә җирлек әһәмиятендәге рекреация максатларындагы аерым саклана торган территория булдырырга.

3. Кушымтага ярашлы, җирлек әһәмиятендәге рекреация максатларындагы аерым саклана торган территориядән файдалануның аерым хокукый режимын билгеләргә.

4. Әлеге карар кул куелган көненнән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) бастырылып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Т. Гарифуллин**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**______________ ел, № ______ карарына**
**кушымта**

**Җирлек әһәмиятендәге рекреация максатларындагы аерым саклана торган территориянең аерым хокукый режимы**

1. Җирлек әһәмиятендәге рекреация максатларындагы аерым саклана торган территория гражданнарның ял итүен, туризмын, физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен билгеләнә.
2. Җирлек әһәмиятендәге аерым саклана торган территориядә:
2.1 Әлеге территориянең рекреация билгеләнешенә туры килми торган эшчәнлек тыела, шул исәптән барлык очракларда да түбәндәгеләр тыела:

аерым саклана торган территориянең сакланышын бозуга китерә торган эшчәнлек;
файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару;
җирлек үзидарә органнары белән килешүдән тыш, туфрагын һәм геологик төзелешен бозуга китерә торган эшчәнлек;
җирлек үзидарә органнары белән килешүдән тыш, гидрологик һәм гидрогеологик режимнарның үзгәрүенә китерә торган эшчәнлек;
җирлек үзидарә органнары белән килешүдән тыш, автомобиль юллары, үткәргеч торбалар, электр тапшыру линияләре һәм башка коммуникацияләр төзү;
гамәлдәге объектларда реставрация эшләреннән тыш, аерым саклана торган табигый территорияләрнең эшләве белән бәйле булмаган сәнәгать, хуҗалык һәм башка объектлар төзү;
аерым саклана торган территорияләрнең эшләве белән бәйле булмаган механик транспорт чараларының хәрәкәте һәм тукталып торуы;
юллардан тыш терлек куу;
оештырылмаган рекреация эшчәнлеге, автотранспорт тукталышлары ясау;
билгеләнгән урыннардан һәм мәйданчыклардан тыш учаклар кабызу;
территорияне чүпләү һәм пычрату;
җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру;
аерым саклана торган территория режимының бозылуына китерә алган башка эшчәнлек төрләре.

2.2 Җирлек үзидарә органнары белән килешү нигезендә ял йортлары, кемпинглар, физик культура һәм спорт объектлары, туристлык базалары, стационар һәм чатырлы туристлык-сәламәтләндерү лагерьлары, балалар туристлык станцияләре, парклар һәм башка шундый ук объектлар төзүгә рөхсәт ителә.

3. Билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек режимын саклау гражданнар һәм юридик затлар өчен мәҗбүри. Җирлек әһәмиятендәге аерым саклана торган территориянең билгеләнгән аерым хокукый режимын бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге кануннарына ярашлы рәвештә административ, җинаять яки башка җаваплылыкка тартылалар.